**КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ**

**ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ**

**КАЗАНСКИЙ МЕЖДУНАРОДНЫЙ ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ ЦЕНТР**

**ЦЕНТР ЯЗЫКОВОЙ СЕРТИФИКАЦИИ ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**

# МАТЕРИАЛЫ ДЛЯ ПРОВЕДЕНИЯ ТЕСТИРОВАНИЯ: НАЧАЛЬНЫЙ УРОВЕНЬ (А1)

**вариант 1**

**КАЗАНЬ 2014**

Фамилиягез ________________________
Исемегез __________________________
Әтиегезнең исеме __________________

Номерыгыз [ ]

# ТЫҢЛАП АҢЛАУ

Башлангыч дәрәҗә: А1.

**25 минут**

## Биремнәр бланкы

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз.
Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.
Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.

### Тест турында кыскача мәгълүмат

Биремнәрне эшләү вакыты: 25 минут
Бүлекләр саны: 5
Биремнәр саны: 25
Баллар: һәр бирем 1 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 25

# ТЫҢЛАП АҢЛАУ ТЕСТЫ

**1 нче бүлек.**

**Сез диалог тыңларсыз. Һәр диалогка бер бирем бирелә. Рәсемгә карагыз. Тәңгәллекләрне билгеләгез. 1-5 биремнәренә тәкъдим ителгән А-Е вариантларыннан шакмак эченә тиешле хәрефне языгыз. Бер хәреф артык икәнен истә тотыгыз. Диалогны ике тапкыр ишетерсез.**




**Үрнәк**.

| | |
|---|---|
| 0 | А |

| | |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| 5 | |

**2 нче бүлек.**

**Диалогны тыңлагыз. 6-10 нчы биремнәрне үтәгез: төшеп калган**

**сүзләрне языгыз. Һәр биремгә бер генә сүз языгыз. Диалогны ике тапкыр ишетерсез.**

**Үрнәк.**

0  Булатның танышы: Айсылу ХАНЫМ.

6 Айсылу  ханым кайдан кайта?  ______________кайта.
7 Айсылу ханым кайда яши?  _____________ .
8 Айсылу ханымның һөнәре._____ __________
9 Балалары. Бер _____________бар.
10 Айсылу ханым нәрсә укыта? Татар___________укыта.

**3 нче бүлек.**

**Диалогны тыңлагыз. 11-15 нче биремнәрне үтәгез: эш-хәлләр белән атна көннәре арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз һәм А-Е хәрефләрен тиешле шакмак эченә языгыз. Диалогны ике тапкыр ишетерсез.**

**Үрнәк.**

0 [кайттым]  Д

| | |
|---|---|
| **0** | **Д** |

| | | |
|---|---|---|
| | А | Дүшәмбе |
| 11 [су коендым] | Ә | Сишәмбе |
| 12 [балык тоттым] | Б | Чәршәмбе |
| 13 [ашадым] | В | Пәнҗешәмбе |
| 14 [укыдым] | Г | Җомга |
| 15 [эшләдем] | Д | Шимбә |
| | Е | Якшәмбе |

**4 нче бүлек.**

**Сез биш кыска диалог тыңларсыз. Һәр диалогка өч җавап варианты булган бер сорау бирелә. Сез һәр диалогны ике тапкыр тыңларсыз. 16-20 нче биремнәрне үтәгез: А, Ә, Б вариантларыннан дөрес булган бер җавапны билгеләгез.**

**Үрнәк.**

0 Булат кем булып эшли?

А) укытучы
Ә) тәрбияче
Б) сатучы

| 0 | А |
|---|---|

16 Айсылу кичә кая барды?
А) бакчага
Ә) театрга
Б) урманга

17 Бүген көн нинди?
А) кояшлы
Ә) җылы
Б) җилле

18 Искәндәр дустына нәрсә бүләк итте?
А) туп
Ә) китап
Б) чәчәк

19 Камил кайда яши?
А) авылда
Ә) чит илдә
Б) шәһәрдә

20 Мансур кибеттән нәрсә алды?
А) тоз
Ә) сөт
Б) ит

**5 нче бүлек.**
**Сез диалог тыңларсыз. 21-25 нче биремнәргә тәкъдим ителгән вариантлардан буш урынга тиешле һөнәрне языгыз. Диалогны ике тапкыр ишетерсез.**

**Үрнәк.**
0 Айсылу ханым – ХИСАПЧЫ. Ул фирмада эшли.

21 Гөлназ ханым – ____________________. Ул ашамлыклар сата.
22 Азат әфәнде – ________________________. Ул йортлар төзи.
23 Галия ханым – ____________________. Ул кешеләрне дәвалый.
24 Венера ханым – ____________________. Ул балалар бакчасында эшли.
25 Камил әфәнде – ____________________. Ул мәктәптә эшли.

Фамилиягез ________________________
Исемегез __________________________
Әтиегезнең исеме __________________

Номерыгыз [                    ]

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ТЕСТ: УКУ ҺӘМ ЯЗУ. ЛЕКСИКА. ГРАММАТИКА

Башлангыч дәрәҗә: А1.

**30 минут**

## Биремнәр бланкы

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз.
Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән.
Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.
Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.
Сорауларыгыз булса, Сез аларны хәзер бирә аласыз. Биремнәрне эшләгәндә, сораулар бирү һәм сөйләшү тыела.

### Тест турында кыскача мәгълүмат

Биремнәрне эшләү вакыты: 30 минут
Бүлекләр саны: 6
Биремнәр саны: 40
Баллар: һәр бирем 1 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 40

**1 нче бүлек.**

**1-6 нчы биремнәрдә тәкъдим ителгән кыскача тасвирламалар һәм сүзләр арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Сүзне тасвирланышы янына языгыз. Ике артык сүз барлыгын истә тотыгыз.**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| АПА | ӘНИ | БАБАЙ | АБЫЙ | ӘТИ | СЕҢЕЛ | ӘБИ | ЭНЕ | ОНЫК |

**Үрнәк.**

0 Әтинең яки әнинең атасы. БАБАЙ

1 Минем әтинең анасы.
2 Миңа һәм минем апама ана.
3 Кыз туганың, синнән ике яшькә олы.
4 Үзеңнән ике яшькә олы ир туганың.
5 Ир кеше, үзенең балаларына ата.
6 Минем ир туганым, миннән ике яшькә кече.

**2 нче бүлек.**

**Текстны укыгыз. Тексттан соң бирелгән 7-12 нче биремнәрдә җөмләләр янында «Әйе» (җөмлә текстның эчтәлегенә туры килә), «Юк» (җөмлә текстның эчтәлегенә туры килми) дип языгыз.**

Мин дустым Галия белән фитнес үзәгенә йөрим. Ул шәһәр үзәгендә урнашкан, тукталыштан ерак түгел. Фитнес үзәге тугыз катлы зур бинаның икенче катында урнашкан. Бүлмәләре якты һәм матур, җиһазлар яңа. Икенче катта көрәш, физик күнегүләр, бию белән шөгыльләнергә мөмкин. Балалар өчен дә дәресләр үткәрәләр. Аста йөзү бүлмәсе дә бар. Монда төркем белән дә, үзең генә дә шөгыльләнергә мөмкин. Монда яхшы хезмәт күрсәтәләр. Бу үзәктә төрле яшьтәге кешеләр шөгыльләнә. Без Галия белән физик күнегүләр ясыйбыз, йөзәргә яратабыз. Атнада ике тапкыр: сишәмбе һәм җомга көннәрне барабыз. Мин монда күптәннән шөгыльләнәм, ә Галия ике ай йөри. Безгә монда бик ошый.

**Үрнәк.**

0 Дуслар атнада ике тапкыр фитнес үзәгенә йөриләр. ӘЙЕ

7 Үзәк тукталышка якын урнашкан.________________.
8 Үзәккә төрле яшьтәге кешеләр йөриләр. ______.
9 Дуслар беренче катта йөзү дәресләренә дә баралар . _______________.
10 Дуслар күптәннән көрәш белән шөгыльләнәләр. ________________.
11 Монда ике ай хезмәт күрсәтәләр.___________________.
12 Дусларга үзәктә шөгыльләнергә ошый. ___________________.

**3 нче бүлек.**

**Диалогларны укыгыз. 13-18 нче биремнәргә туры килгән А, Ә яки Б вариантларыннан дөрес җавапны сайлап алыгыз.**

**Үрнәк.**

0 – Хәлләр ничек?

А – Рәхмәт, яхшы.
Ә – Рәхмәт, ярар.
Б – Без танышлар.

| | |
|---|---|
| 0 | А |

13 – Исәнме!

А – Сәлам!
Ә – Сау бул!
Б – Сәламәт бул!

14 – Гаиләгез ничек?

А – Бик шат!
Ә – Бик дөрес!
Б – Бик әйбәт!

15 – Рәхим итегез!

А – Рәхмәт, берни түгел.
Ә – Рәхмәт, ярый.
Б – Рәхмәт, кирәк.

16 – Керергә ярыймы?

А – Ярар.
Ә – Ярамый.
Б – Яхшы.

17 –Таныш булыгыз, бу минем дустым!

А – Мин шат!
Ә – Мин риза!
Б – Мин хәзер!

18 – Гафу итегез, сорарга ярыймы?

А – Мөмкин.
Ә – Сорый.
Б – Шулай.

**4 нче бүлек.**

**Төшереп калдырылган сүзләре булган хикәяне укыгыз һәм 19-24 нче биремнәрне үтәгез. Текст ахырында бирелгән сүзләрдән һәр буш урынга туры килгән берсен сайлап алып языгыз. Ике артык сүз барлыгын онытмагыз.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| КОТЛАДЫЛАР | КУНАКЛАР | КҮҢЕЛ АЧТЫ | КЫЗЫБЫЗНЫ |
| ОШАДЫ ЛӘКИН | ЧӨНКИ | УНСИГЕЗ | ҖЫРЛАДЫ |

Без (0) __________ чакырырга яратабыз. Туганнарыбыз, дусларыбыз безгә кунакка еш киләләр. Гадәттә, туган көннәрне без гаиләләребез белән бергә үткәрергә яратабыз.

Бу ялда да безгә кунаклар килде, (19) _______________ кызым Алсуның туган көне булды. Аңа (20) ________________ яшь тулды. Без өстәл әзерләдек һәм тәмле ашлар пешердек. Кызым да миңа булышты. Ирем кибеттән бүләккә чәчәкләр сатып алды.

Көндез кызымның дуслары килде. Аны туган көне белән котладылар, татарча аудиокитап бүләк иттеләр. Кич белән туганнарыбыз килде. Алар да (21) ________________ туган көне белән котладылар. Алсуга бүләкләр бирделәр һәм матур сүзләр әйттеләр. Әтисе гармунда уйнады, татар җырлары (22) ________________, ә кызым пианинода уйнады. Кунаклар да (23) ________________ . Бу көн кызыбызга да, туганнарыбызга да бик (24) ________________ .

**Үрнәк.**
Без (0) <u>КУНАКЛАР</u> чакырырга яратабыз.

**25 Биремне үтәү өчен, текстның исеме буларак туры килгән А, Ә яки Б вариантын билгеләгез.**

А Туган көн.
Ә Әниләр көне.
Б Гаилә бәйрәме.

**5 нче бүлек.**

**Хикәяне укыгыз. 26-35 нче биремнәрне үтәгез. Буш урыннарга хикәянең эчтәлегенә туры килгән бер яки ике сүз языгыз.**

**Дустымның фатиры**

Дустым Әмир гаиләсе белән Казан шәһәрендә яши. Алар күпкатлы йортта өч бүлмәле фатирда яшиләр. Фатирлары бишенче катта урнашкан. Фатир зур түгел, ләкин матур, чиста һәм җылы. Фатирда өч бүлмә бар: кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе һәм балалар бүлмәсе. Иң зур бүлмә – кунак бүлмәсе. Анда түгәрәк өстәл һәм урындыклар тора. Йокы бүлмәсе уңда урнашкан. Анда яңа карават белән шкаф тора. Аш бүлмәсе сулда. Аш бүлмәсендә өстәл, урындыклар, шкаф һәм суыткыч бар. Балалар бүлмәсе бик матур, анда ике карават, кечкенә өстәл, шкаф тора. Бүлмәләрдә җиһазлар күп түгел. Фатир тәрәзәләре кояшлы якка карый. Дустымның хатыны яңа җиһазлар сатып алырга тели. Ләкин Әмиргә иске җиһазлар ошый.

Дустымның авылда йорты да бар. Алар бу йортны былтыр сатып алдылар. Җәен алар балалары белән анда яшиләр. Кышын шәһәрдә торалар. Бу авыл бик матур урында урнашкан. Янында кечкенә елга, урман да бар. Бу авыл шәһәрдән ерак түгел. Анда автобус белән дә барырга мөмкин. Гадәттә, аларга ял көннәрендә шәһәрдән туганнары, дуслары да киләләр. Мин дә аларда кунакта булдым. Миңа бу авыл бик ошады. Мин дә бу авылда йорт сатып алырга телим.

**Үрнәк.**

**0** Әмирнең гаиләсе Казан <u>ШӘҺӘРЕНДӘ</u> яши.
26 Фатир _____________ катлы бинада урнашкан.
27 Кунак_____________________түгәрәк өстәл бар.
28 Йокы бүлмәсендә _____________ карават та бар.
29 Суыткыч _____________ урнашкан.
30 Дустымның фатиры _____________ түгел.
31 Әмирнең гаиләсе _____________ авылда яши.
32 Йорт шәһәрдән _____________ бер авылда урнашкан.
33 Ял_____________ туганнары да кайталар.
34 Мин дустым гаиләсендә _____________ булдым.
35 Теләгем - авылда _____________ сатып алырга.

**6 нчы бүлек.**

**Текстны укыгыз. 36-40 нчы биремнәрдә А, Ә яки Б**

**вариантларыннан дөрес җавапны сайлагыз. Алар грамматик һәм лексик яктан текстның эчтәлегенә туры килергә тиеш. Сайлаган вариантыгызны текстка языгыз.**

## Минем яңа дустым Айсылу

Мин кичә бер (0) ____________ белән таныштым. Сезне дә бу кыз белән таныштырырга телим. Ул бик матур һәм (36) ____________ кыз. Аның исеме – Айсылу. Айсылуга егерме яшь. Ул уртача (37) ____________ ябык. Аның чәчләре озын һәм кара. (38) ____________ коңгырт.

Айсылу да безнең институтта укый. Мин өченче курста укыйм, ул икенче курста. Ул (39) ____________булырга тели. Ул миңа бик ошый. Мин аны бүген кинога (40) ____________.

**Үрнәк.**

Мин кичә бер (0) КЫЗ белән таныштым.

**0 А** кызга **Ә** кызны **Б** кыз

| | |
|---|---|
| 0 | Б |

36 **А** акыл **Ә** акыллы **Б** акылсызлык
37 **А** буйлы **Ә** буй **Б** буйны
38 **А** күзлек **Ә** күзләре **Б** күзле
39 **А** укучы **Ә** укы **Б** укытучы
40 **А** чакырдым **Ә** чакырдык **Б** чакыралар

**Җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз.**